КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 31 март № 186

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы мәсьәләләре» 2007 ел, 15 ав-густ, 388 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы мәсьәләләре» 2007 ел, 15 август, 388 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 ел, 20 сентябрь, 492 нче; 2007 ел, 29 декабрь, 788 нче; 2008 ел, 17 ноябрь, 818 нче; 2009 ел, 22 июнь, 418 нче; 2010 ел, 1 апрель, 217 нче; 2010 ел, 6 декабрь, 1003 нче; 2010 ел, 10 декабрь, 1041 нче; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2011 ел, 13 декабрь, 1013 нче; 2012 ел, 2 июль, 576 нчы; 2012 ел, 17 сентябрь, 774 нче; 2013 ел, 22 май, 341 нче; 2013 ел, 22 август, 592 нче; 2013 ел, 26 октябрь, 799 нчы; 2013 ел, 19 ноябрь, 896 нчы; 2014 ел, 18 апрель, 253 нче; 2014 ел, 31 май, 372 нче; 2014 ел, 16 сентябрь, 665 нче; 2014 ел, 24 ноябрь, 902 нче; 2014 ел, 12 декабрь, 983 нче; 2015 ел, 11 июнь, 433 нче; 2015 ел, 17 сентябрь, 684 нче; 2015 ел, 14 октябрь, 767 нче, 2015 ел, 25 декабрь, 984 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы турындагы нигезләмәгә (алга таба – Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.3 пунктка түбәндәге эчтәлекле 3.3.30 пунктча өстәргә:

«3.3.30. Юридик затларның документларын карап тикшерә һәм Татарстан Республикасы Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы эшчәнлеге тармагындагы масштаблы инвестицион проектларның социаль яклау һәм социаль хезмәт күрсәтү объектларының Татарстан Республикасы Җир кодексының 33.3 статьясында күрсәтелгән критерияләргә, мондый критерияләрнең Татарстан

Республикасы Президенты тарафыннан билгеләнгән сыйфат һәм (яки) сан күрсәткечләренә туры килүе турында бәяләмә проектларын килештерә.»;

Нигезләмәгә Кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы турындагы нигезләмәгә кушымта

Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы предприятиеләр, учреждениеләр һәм бүтән оешмалар белән үзара бәйләнештә булган икътисадый эшчәнлек төрләре исемлеге

| ИЭТГРК | Икътисадый эшчәнлек төрләре исемлеге |
|---|---|
| 74.50 <*> | Эшче көчләр яллау һәм персонал сайлау |
| 74.50.1<*> | Эшче көчләр яллау буенча хезмәтләр күрсәтү |
| 75.3 <*> | Мәҗбүри социаль тәэмин итү өлкәсендә эшчәнлек |
| 75.30 <*> | Мәҗбүри социаль тәэмин итү өлкәсендә эшчәнлек |
| 80.22.2 <*> | Урта һөнәри белем |
| 80.30.3 <*> | Югары һөнәри белеме булган белгечләр өчен өстәмә һөнәри белем бирү (квалификация күтәрү) мәгариф учреждениеләрендә укыту |
| 85.3 <*> | Социаль хезмәтләр күрсәтү |
| 85.31 <*> | Яшәүне тәэмин итеп, социаль хезмәтләр күрсәтү |
| 85.32 <*> | Яшәүне тәэмин итмичә, социаль хезмәтләр күрсәтү |

---

<*> Стандартлаштыру һәм метрология буенча Россия Федерациясе Дәүләт комитетының 2001 ел, 06 ноябрь,454-ст. карары белән расланган Икътисадый эшчәнлек төрләренең гомумроссия классификаторы нигезендә расланган икътисадый эшчәнлек төрләре кодлары билгеләмәсе.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков